# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлегенең Березовая Грива авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

18 декабрь 2021 е.

№ 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге составына керүче Березовая Грива авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:
- җирлек юлларына вак таш җәю һәм карап тоту;
- балалар мәйданчыгына беседка әзерләү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Лебедино авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

2. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районынын**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И.Тюкарев**